**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 21 ноябрь № 885

г. Казань

Татарстан Республикасы бюджет акчасы исәбеннән Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $20^{1}$ һәм $20^{1-2}$ статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджет акчасы исәбеннән Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасының бюджет һәм автоном учреждениеләре төп чараларына капитал салулар рәвешендә Татарстан Республикасы дәүләт милкенең капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләре бирү турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1172 нче;

«Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләренең һәм Татарстан Республикасы автоном учреждениеләренең төп чараларына капитал салулар рәвешендә Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләре бирү шартлары турында» 2012 ел, 2 март, 183 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\885.docx